**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «16» мартыннан № 32-245

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы федераль законнарга, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июльдәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының нигезләмәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (№2-9, 16.10.2015 ел, №9-32,11.02.2016 ел, №18-82, 28.09.2016 ел, №20-103, 14.12.2016 ел, №25-132, 17.04.2017 ел, №28-150 17.08.2017 ел, №31-180, 14.12.2017, №37-209, 25.05.2018 ел, №43-252, 13.12.2018, №50-299, 05.07.2019, №61-378, 04.06.2020 ел, №10-70, 02.06.2021ел, №16-124, 09.12.2021, №24-181 от 7.07.2022 ел карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6(1) статьяның нумерациясендә, җәяләрне нокталар белән алмаштырып, төшереп калдырырга «6.1»;

1.2. 13(1) статьяның нумерациясендә, җәяләрне нокталар белән алмаштырып, төшереп калдырырга «13.1»;

1.3. 13.1 статьяның 3 өлешендәге өченче абзацында «район сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба - сайлау комиссиясе) тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 13.1 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. Муниципаль сайлауларны әзерләү һәм үткәрү сайлау комиссияләретарафыннан аларның компетенциясе кысаларында башкарыла.»;

1.5. 13.1 статьясына түбәндәге эчтәлекле 9 өлеш өстәргә:

«9. Җирле үзидарә органнарына сайлаулар әзерләү һәм уздыру, автоматлаштыру чараларын эксплуатацияләү һәм үстерү, сайлауларны оештыручыларны һәм сайлаучыларны укыту белән бәйле чыгымнар бу максатларга җирле бюджеттан бүлеп бирелгән акчалар хисабына сайлау комиссияләре тарафыннан башкарыла. Күрсәтелгән чыгымнарны финанслау җирле бюджет чыгымнарын бүлү турында расланган бюджет язмасы нигезендә, сайлаулар билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан (бастырылган) көннән ун көннән дә соңга калмыйча, башкарыла.».

1.6. 13(2) статьяның нумерациясендә, җәяләрне нокталар белән алмаштырып, төшереп калдырырга «13.2»;

1.7. 13.2 статьяның 5 өлешендә «Район сайлау комиссиясен» сүзләрен «сайлау комиссиясен» сүзләренә алмаштырырга;

1.8. 13 (2) статьяның 8 пунктындагы беренче җөмләдә «Район сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләрен «сайлау комиссиясе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.9. 13.2 статьяның 12 өлешендә «Район сайлау комиссиясе.» сүзләрен «сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 19 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын һәм аларны үткәрү урынын күрсәтеп, гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш, Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында, шулай ук «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш»;http://pravo.tatarstan.ru

1.11. 19 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гавами тыңлаулар һәм муниципаль норматив хокукый акт проекты басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән башлап, Яңа Чишмә муниципаль районы халкы район Башлыгына муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча, гавами тыңлауларга чыгарылган, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрергә хокуклы.

Кисәтүләр һәм тәкъдимнәр җибәрү гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне берләштерүне оештыра һәм аларны гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерә.»;

1.12. 19 статьяның 9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктлары территориясендә урнаштырылган махсус мәгълүмати стендларда, һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында гавами тыңлаулар уздырганнан соң 5 календарь көненнән дә соңга калмыйча басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш»;

1.13. 29 статьяның 1 өлешендәге дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.14. 29 статьядагы 7 өлешнең 2 пунктындагы а пунктчасында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

1.15. 29 статьядагы 7 өлешнең 2 пунктындагы б пунктчасында:;

- «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

- «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.16. 29 статьяның 7.2. өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.17. 29 статьяның 7.3. өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.18. 33 статьяның 16 пунктында «район сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую» сүзләрен төшереп калдырырга;

39 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:

«13) алты ай дәвамында район Советының барлык утырышларында нигезле сәбәпләрсез депутатның булмавы.»;

1.20. 39 статьяның 7 өлешендәге икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.21. 42 статьяның 5 өлешендәге 2 пунктында а пунктчасында:

- «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

1.22. 42 статьяның 5 өлешендәге 2 пунктында б пунктчасында:

- «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

- «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.23. 44 статьяның 4 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.24. 44 статьяның 5 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.25. 45 статьядагы 7 өлешнең 2 пунктындагы а пунктчасында:

- «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

1.26. 45 статьядагы 7 өлешнең 2 пунктындагы б пунктчасында:

- «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

- «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.27. 50 статьяның 2 өлешендәге икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.28. 53 статьяның 2 өлешендәге 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән алыштырырга;

1.29. «Сайлау комиссиясе» VIII бүлеген төшереп калдырырга.

1.30. 68(1) статьяның нумерациясендә, җәяләрне нокталар белән алмаштырып, төшереп калдырырга «68.1»;

1.31. 83 статьяның 7 өлешендәге өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләре белән

алыштырырга;

2. Әлеге карар, әгәр үз көченә керүнең башка сроклары законнарда каралмаган булса, дәүләт теркәвенә алынганнан соң, рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алу өчен Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштырыру ысулы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы — В.М. Козлов